| | | |
|---|---|---|
| **ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

6 май 2014 ел Казан шәһәре № 3-2/э

***“Татарстан Республикасы халкы һәм аңа тигезләштерелгән кулланучылар категорияләре өчен электр энергиясенә бәяне (тарифны) 2014 елга билгеләү турында” 20.12.2013 №3-18/э Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында***

“Электр энергетикасы турында” 26.03.2003 №35-ФЗ Федераль законы нигезендә, “Электроэнергетика өлкәсендә җайга салынучы бәяләрне (тарифларны) билгеләү” 29.12.2011 №1178 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары һәм “Электр энергиясеннән (куәтлелегеннән) файдалану социаль нормаларын куллану һәм билгеләү тәртибе турында, электр энергиясеннән (куәтлелегеннән) файдалану социаль нормаларын куллану һәм билгеләүгә кагылган Россия Федерациясе Хөкүмәте кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында” 22.07.2013 №614 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, 15.06.2010 №468 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты кагыйдәнамәсе нигезендә, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР чыгарды:

1. “Татарстан Республикасы халкы һәм аңа тигезләштерелгән кулланучылар категорияләре өчен электр энергиясенә бәяне (тарифны) 2014 елга билгеләү турында” 20.12.2013 №3-18/э Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2, 4нче пунктларны һәм карарга 2нче кушымтаны үз көчен югалткан дип исәпләргә;

1нче кушымтаның 3нче пунктында “Авыл торак пунктларында яшәүче халык” сүзләреннән соң “<3>” астөшермәсен өстәргә;

“<4>” астөшермәсен һәм карарның 1нче кушымтасындагы искәрмәне үз көчен югалткан дип исәпләргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты Рәисе М.Р.Зарипов